Tatar16.ru

# Амур Фәләх

(1965 – )

*« Сатмас егет илен алтын көмешләргә,*
*Әгәр югалтмаса вөҗданын.*
*Алтынны ул чүпкә санар,*
*Иң кыйммәтле күрер Ватанын »*



- *Амур Фәләх — татар язучысы, журналист. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы* (2012).
- *Фәләхов Амур Нур улы* 1965 *елның 10 сентябрендә Татарстанның Мамадыш районыЯңа Комазан авылында колхозчылар гаиләсендә дөньяга килә.* 1972-1982 *елларда Көек-Ерыкса урта мәктәбендә белем алгач, Казан дәүләт университетына укырга керә. Ләкин, сәламәтлеге какшау сәбәпле, укуын калдырып торыга туры килә. Журналистика факультетына яңадан* 1986 *елдагына әйләнеп кайтып, читтән торып тәмамлый.*
- 1988-1999 *елларда Ижау шәһәрендә яши (Удмуртия). Башта "Ижсталь" заводында столяр-станокчы булып хезмәт куя. 1992 елның ноябреннән*

Tatar16.ru

Tatar16.ru



- шәһәрдә чыга башлаган «Яңарыш» татар газетасына күчә. Әүвәлдә махсус хәбәрче, аннары җаваплы сәркәтип була. 1997-1999 елларда “Яңарыш”ның баш мөхәррире вазыйфасын башкара.
- 1998 елда Русия журналистлар берлегенә кабул ителә. 2001-2008 елларда

- Чаллыда чыгып килүче «Мәйдан» әдәби-нәфис, иҗтимагый журналының җаваплы секретаре, публицистика бүлеге мөдире, һәм бүлек редакторы вазыйфаларын башкара. Чаллы шәһәре инвалид спортчыларның “Идел-Урал” хәйрия фонды матбугат үзәгендә эшли.
- Хәзерге вакытта — "Безнең фикер" газетасының оештыручысы һәм баш мөхәррире.

Tatar16.ru

- Публицистик язмалар белән беррәттән әдәби әсәрләр дә иҗат итә. Язмалары матбугатта Амур Фәләх, Әмир Ханов, Нур Әхмәт, Фәләх Комазани псевдонимнары белән нәшер ителә. “Таш бәгырь” җыентыгы (2004) һәм “Мәйдан” журналында басылып чыккан тарихи-публицистик язмалары өчен

Tatar16.ru

- *2007 елда Шәйхи Маннур исемендәге премиягә лаек була. 2010 елда Татарстан китап нәшриятында "Зимагур" дип аталган әсәрләр җыентыгы дөнья күрә. 2015 елда Удмуртия Язучылар берлеге*
- *һәм Татарстан язучылар берлегенең уртак Риза Шәфи исемендәге әдәби премиясе белән бүләкләнә.*
- *2012 елдан — Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*